СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

18 ноябрь, 1998 ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 131 (8288) | Бәясе билгеләнгәнчә

# ЭШ КИМЕМИ БӘЙРӘМ ҮТСӘ ДӘ...

## ХЕЗМӘТКӘ - ХӨРМӘТ

***Авыл хуҗалыгы өлкәсендә озак еллар һәм нәтиҗәле эшләгәннәре өчен һәм Авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү промышленносте хезмәткәрләре көне уңаеннан Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек министрлыгының Мактау кәгазе белән бүләкләнүчеләр арасында безнең районнан:***

"Киекле" крестьян хуҗалыклары ассоциациясе рәисе **Наил Шакир улы ШАРАПОВ;**

Хафизов исемендәге хуҗалык комбайнчысы **Александр Егорович ДОНСКОВ;**

Муса Җәлил исемендәге хуҗалыкның дуңгыз караучысы **Исхак Ислам улы ХӘЙРУЛЛИН** да бар.

Бүләкләнүчеләрне чын күңелдән котлыйбыз!

## "УҢЫШ БӘЙРӘМЕ" УҢЫШЛЫ БУЛДЫ

Күптән түгел безнең мәктәптә дә "Уңыш бәйрәме", ягъни "Көзге бал" булып узды.

Биредә мәктәп укучылары өч төркемгә бүленде.Беренче төркем "Сөмбелә", икенчесе "Зәлидә" һәм өченчесе "Шаян шоу" күренешләрен күрсәтергә тиешләр иде. Укытучылар җитәкчелегендә төркемнәрнең чыгышлары бер атна дигәндә әзер булды. Вакыт аз булса да, укучылар һәр уенны бүгенге тормыш таләпләренә җавап бирерлек итеп әзерли алдылар. Бигрәк тә "Зәлидә"не уйнаучы кызлар бу алымны оста итеп кулланганнар. Һәр укучы үзләренең яраткан укытучылары булып уйнап күрсәттеләр.

Ә менә X класс укучылары Сәгыйров Альберт һәм Мотыйгуллин Рамилнең чыгышларын көлми карый алмадылар. Алар бүгенге базар хикмәтләрен чагылдырдылар. Ике әби булып уйнадылар, тамашачыларның күңелләрен күтәрделәр...

Әйе, уен булгач бар да була ул. Кемдер җиңелергә, ә кемдер җиңәргә тиеш. Шулай итеп, "Зәлидә" һәм "Шаян шоу" төркемнәре беренче, ә "Сөембикә" икенче урынны алды.

Соңыннан барлык укучылар һәм укытучылар рәхәтләнеп үзләре әзерләгән сый - хөрмәттән авыз иттеләр, күмәкләп биеделәр.

**Хәлим ӘЛИМОВ.**
**Зирекле авылы.**

Равил Галиәкбәров

## ИГЕНЧЕ

*Муллык кирәк илгә,*
*Муллык кирәк җиргә!*
*Нурлар кирәк көнгә,*
*Нурлар - табын түргә!*
*Зур көч куеп җиргә бирелүче,*
*Тоеп җир - ананың сагышын,*
*Җаны - тәне белән тик игенче*
*Чишә ала икмәк язмышын!*
*Вөҗданы һәм аның намус хисе*
*Ил байлыгы арту өчен дә,-*
*Хуш аңкыган тәмле икмәк исе,*
*Башкаларның яшәү көчендә!*
*Ул сөенә илнең кырларына,*
*Башкарган эш, алтын кулларына!*
*Моңнар сала җирнең җырларына,*
*Нурлар өсти галәм юлларына!*
*Изге бурычын үти җирне иңләп,*
*Батырлыкка аның тиң эше!*
*Алтын бөртек, өстәлдәге икмәк -*
*Тырыш хезмәт, йөрәк җимеше!*
*Тирен түккән татлы хезмәттә,*
*Ул лаеклы олы хөрмәткә!*
*Илгә - көнгә муллык бирүче,*
*Җир бәхете - данлы игенче!*



Н.АЗИЗОВ фотосы.

***Рәсемдә: "Өмет" агрофирмасы комбайнчысы Иван Николаев. Быелгы уракта да ул үзенең "ДОН"ы белән фидакарь хезмәт куйды, шуңа да ул хуҗалыкның иң күп ашлык суктыручы игенчеләре исемлегендә ышанычлы урын алды.***

Терлекчелектә - кыш

# ИҢ МӨҺИМЕ - ТӘРТИП

Шундый ук баш астында чыккан алдагы язмада ("Дуслык", № 129) ике - РСУ һәм "Агрохимсервис" ярдәмче хуҗалыкларының терлекчелек фермаларындагы эшнең торышы турында сүз башлаган идек. Алдагы язмада әйткәнебезчә, терлекчелектәге теге яки бу җитешсезлекләр күпмедер дәрәҗәдә шактый гына башка хуҗалыкларга да кагыла, ә шул кимчелекләрне төзәтми торып тармакта хәлне тотрыклыландыру турында сүз дә алып барырга мөмкин түгел, ә бүген терлекчелек - авылда бердәнбер акча чыганагы бит. Анысын бу арада авыл халкы үзе дә тойгандыр, чөнки озак вакытлар кулларына тере акча тотып карамаган "колхозчылар"га сөт сатудан ярыйсы гына акча өләшенде, һәм бу әле соңгысы булмаячак. Шунысын да әйтик, акча һәр хуҗалыкка да керткән өлешенә карап, ягъни саткан продукциясеннән чыгып бирелде. Димәк, ничек эшләсәк, шулай яшәрбез дигән сүз һаман да дөрескә чыгып килә.

Инде башлаган сүзгә кайтыйк. Алдагы язмада РСУ ярдәмче хуҗалыгында мөгезле эре терлек фермаларындагы хәлләргә тукталган идек. Күршеләрнекеннән шактый азрак булса да, "Агрохимсервис" ярдәмче хуҗалыгында да бар андый мал. Савым сыерлар нигездә ике - "Руслан" һәм "Петровский" кооперативларында тупланган. Беренчесенә соңгы вакытта "Каенлык" һәм "Берлек" кооперативлары да кушылды һәм аның мөгезле эре терлекләре Октябрина фермасында тотыла. Былтыр биредә сыерларны бәйләүсез асрауга күчеп, саву залы көйләп җибәргәннәр иде. Ул чакта монда шактый җитешсезлекләргә тап булсак та, кооперативның әле яңа гына мөстәкыйль рәвештә эшли башлавын, һәм ул җитешсезлекләрнең тырышканда бетермәслек булмавын искә алып, алар хакында газетада зурдан сүз кузгатмадык. Бер уйлаганда, дөрес тә эшләгәнбез икән әле. Бу юлы шул ук фермада хәлнең бөтәнчә булуына куанып кайттым. Былтыр сыерлар корсак астына кадәр җитәрлек тирескә чумган абзарда хәзер җиңелчә аяк киеме белән йөрергә була, саву залында да тәртип. Ташлаткан сыерлар аерым абзарда тотыла, бозаулату һәм бозаулар бүлегендә дә хәл элеккe кебек начар түгел. Дөрес, әлеге дә баягы утлыклар проблемасы биредә дә бар, әмма анысын тиз арада хәл итәргә ышандыралар - кардаларны ныгытырга да, башка максатларга да җитәрлек итеп агач кискәннәр инде.

(Ахыры 2нче биттә).

БЕЛМИ КАЛМАГЫЗ, КИЛМИ КАЛМАГЫЗ

## 29 НОЯБРЬДӘ - АНА КӨНЕ

Әни... Күңелебездәге иң изге бар нәрсә һәм яхшылык шушы исем белән бәйле. 29 ноябрьдә Татарстанда беренче тапкыр Ана көне уздырылачак. Димәк, бүген әниләребезнең - улын яки кызын берьялгызы тәрбияләүчеләренең дә, күп балаларының да, предприятиедә штат кыскартылу сәбәпле эшсез калганнарының да - күпсанлы проблемаларына тагын бер тапкыр җитди игътибар итәр өчен форсат бар. Күп балалы гаиләдә үсүче гарип балаларга "Игелек һәм шәфкатьлелек" акциясе кысаларында матди ярдәм күрсәтүне дә, коллективларда яшь гаиләләр белән очрашу кичәләре үткәрүне дә, аеруча мохтаҗларга җылы киемнәр җыюны да, хатын - кызлар активының кайбер гаиләләрнең өйләренә баруын оештыруны да күздә тота бу чара.

Хатын кызларыбызның сәламәтлеге - милләтебезнең саулыгы ул. Шуңа да район үзәк сырхауханәсенең хатын - кызлар консультациясендә 19 һәм 26 ноябрьләрдә өйдә утыручы аналарны тирәнтен карау оештырылачак. Бу ике көндә профессиональ консультация дә, киңәшләр һәм күпсанлы сорауларга җавап та алырга мөмкин булачак. Сезне белгеч - табиблар көтәчәк.

***Медицина каравы бушлай үткәрелә.***

## ЯШЬЛӘР ҮЗӘГЕ ЧАКЫРА

Һәркемнең дусты булырга тиеш. Шул фикер нигезендә шәһәрнең Яшьләр үзәгендә яңа матур традиция туарга тора - җомга кичләрендә биредә танышып үзара аралашу, фикерләр һәм уйлар белән бүлешү, бергәләп яраткан көйләрне тыңлау, бию максатында бер төрле яшьтәге кешеләр җыелачак. 20нче ноябрьдә кичке сәгать 8дә Нурлат Яшьләр үзәгендә 20 - 25 яшьлекләр өчен тематик кичә булачак. Килегез! Программа кызык булырга охшый, анда катнашучыларның кәефе көр булуын телибез. Ә Яшьләр үзәге коллективы киләчәктә 30, 40 яшьлекләр белән дә дустанә очрашулар оештыруны ниятли.

***"Илдан" фирмасы***
***район мәдәният йортында 19 - 20 ноябрьдә иртәнге 9дан кичке 5кә кадәр ярминкә - сату үткәрә.***

**САТУДА:**

- төрле мех якалы кышкы пальтолар;
- мех пальто һәм ярым пальтолар;
- мех баш киемнәре;
- мех курткалар һәм кайры туннар;
- көзге пальтолар.

Матбугатка язылу бара

## МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ КҮРСӘТМӘСЕ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 1999 елның беренче яртысына республика, шәһәр, район газеталары һәм журналларына язылу кампаниясен оештыру турында күрсәтмә чыгарды. Бу кампания шушы елның 25 декабрендә тәгамлләнә. Министрлыклар, дәүләт комитетлары, ведомстволар, шәһәр һәм район хакимиятләре, предприятиеләр, учреждение һәм оешмалар җитәкчеләре үз буйсынуларындагы китапханәләр, мәктәп учреждениеләре, сәламәтлек саклау, мәдәният оешмалары һ.б. өчен газета - журналларга язылуны оештыру чараларын күрергә,шулай ук, мөмкин булганча, сугыш һәм хезмәт ветераннарына, инвалидларга һәм аз тәэмин ителгән гаиләләргә вакытлы матбугатка язылу өчен матди ярдәм күрсәтергә тиешләр.

Республика шәһәрләре һәм районнары хакимиятләренә язылу кампаниясенең барышын контрольдә тотарга, исәп - хисап ясауны үз вакытында гамәлгә ашыруда "Татарстан почтасы" элемтә идарәсе предприятиеләренә булышлык итәргә кирәк. "Татарстан" дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар кампаниясенә республикада чыга торган вакытлы матбугатны үзара файдалы нигездә рекламалау өчен эфир вакытын бирергә тәкъдим итәлде.

**("Ватаным Татарстан"нан).**

### «ДУСЛЫК»КА ЯЗЫЛДЫГЫЗМЫ ӘЛЕ?

***1999 елның беренче яртысы өчен "Дуслык" ("Дружба", "Туслах") район газетасына язылу бәясе - 25 сум 20 тиен. Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм инвалидларга, Әфган сугышында булучыларга, Чернобыль атом электр станциясендәге фаҗига нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыларга тиешле документлар нигезендә 50 процент ташлама ясала.***

### НОЯБРЬДӘ МАГНИТЛЫ КӨННӘР

*18 ноябрь чәршәмбе (14 - 16 сәг.)*
*22 ноябрь якшәмбе (15 - 17 сәг.)*
*25 ноябрь чәршәмбе (11 - 13 сәг.)*
*28 ноябрь шимбә (12 - 14 сәг.)*

Үзебезнең һәм якыннарыбызның, тирә - күршеләребезнең сәламәтлегенә игътибарлы булыйк.

## *Терлекчелектә - кыш*

# ИҢ МӨҺИМЕ - ТӘРТИП

*(Ахыры. Башы 1нче биттә).*

Бер үк вакытта, терлекчелек бөтенләй беткән Берлек фермасына да җан өрәләр - биредә ике абзарны маллар ябарлык хәлгә кертә башлаганнар. Билгеле, ул эшкә алданрак тотынсалар да яхшы буласы иде, әмма, соң булса да уң булсын дигәндәй, бирегә буаз таналар алып кайтып урнаштырып куйсалар, "Руслан" кооперативының савым көтүе ишәя башласына өмет бар. Ә биредә, алда әйткәнебезчә, малларның баш санын торгызу иң көнүзәк проблема булып тора әле.

Ә менә хуҗалыкның "Петровский" кооперативында исә мөгезле эре терлекләр, шул исәптән сыерлар саны былтыргыдан күбрәк булса да, аларны карау җиренә җиткереп оештырылмаган әле. Аерым алганда, Петровский фермасында савым сыерлар группаларга да бүленмәгән, цех системасы да юк. Ә бу бит нәсел эшенең дә үзагымга куелганлыгы турында сөйли. Озакламый бозаулыйсы сыерларның рационына да игътибар бирергә кирәк, шунсыз сәламәт үрчем алуга өмет итәсе дә юк. Ул яктан Сосновка фермасында да бозаулату һәм бозаулар абзарларындагы малларга игътибарны арттырасы бар әле.

Ике хуҗалык та элек - электән дуңгызчылык белән шөгыльләнәләр. Шуңа да бу тармакта эшнең торышы белән аерым кызыксындык. Шунысы куанычлы, "Агрохимсервис" кооперативларында дуңгызчылыкны игътибар үзәгендә тоталар. Сүз беренче чиратта "Руслан" һәм "Нива"кооперативлары турында - аларның җитәкчеләре эшне дә инде бетүгә барган шушы тармакны аякка бастырудан башладылар бит, тырышлыкның нәтиҗәсе күз алдында - икесендә дә икешәр абзар тәртипкә китереләп, аларда яшь үрчем дә, симертүдәге маллар да ишле, "Нива"да дуңгызларның баш саны узган елгыдан йөз башка күбрәк. Ике кооперативта да язга шактый ук ишле үрчем алуга исәп тоталар, "Руслан"да шушы максатка менә дигән җәйге лагерь да әзерләп куйганнар инде. Тик әле бүген булган малларны исән - сау кышлатып чыгу турында да кайгыртырга кирәк - абзарларны җылыту чарасын күрү шарт.

Ә менә РСУ ярдәмче хуҗалыгында дуңгызчылыкта эшләр һич мактанырлык түгел. Былтыр да бу хуҗалык өчен әллә ни күп булмаган дуңгызларның саны быел тагын 200 башка кимегән, һәм тармакка игътибар алга таба да искечә калганда, хәлнең тагын да начараюы бик мөмкин. Эш шунда ки, былтыр биредә яңабаштан бер абзар җиткезергә тотынганнар һәм аны кышка өлгертергә дә ниятләгәннәр иде. Әмма, ни гаҗәп, төзелеш оешмасына караган хуҗалыкта да шул эшне ахырына җиткерә алмаганнар - әле бүген дә әзер түгел ул. Җитәкчелекнең тармакка мөнәсәбәте менә кайда ачык чагыла! Ә бит шул абзарның өлгерәсенә өметләнеп, гамәлдәгеләренә кул да тимәгән. Ул абзарлардагы тәртипсезлекне үз күзең белән күрергә кирәк. Әнә шулай, сөтчелек тармагында эшләре ярыйсы гына барган хуҗалыкта дуңгызчылыкта эшне үзагымына куюларын танырга туры килә. Ә бит, сүзебезнең башына әйләнеп кайтсак, бу тармакның иң тиз табыш бирүче икәнлеген тагын бер кат искәртергә мәҗбүр булабыз. Бүген бит берәүдән дә ярдәм көтәсе юк - үз көнеңне бары үзең генә күрәсе.

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**

# ИХЛАС КИТАПНЫҢ АВТОРЫ БУЛЫГЫЗ...

Мин бу хатны 1998 елның сентябрендә Нурлат шәһәрендә булып киткәннән соң Көнбатыш Двина буйларыннан язам.

Нурлатка минем беренче тапкыр гына килүем, ләкин соңгысы булмас, ахры. Анда минем әнием туган, аннары белоруска кияүгә чыккан. Шуңа күрә сезнең яклар минем күңелемә дә якын хәзер.

Вагон тәгәрмәчләре моңсу итеп Ва -тан дигән сүзне тукыйлар сыман. Ә бит ул гаҗәеп киң дә, зур да иде - таркалды. Татарстан белән Белорусь ерак гасырлардан бирле абыйлы - сеңелле кебек яши белә иделәр. Бүген әнием туган якның чит илгә әверелүен күрү гаҗәеп авыр миңа. Ул мәрхүмә инде. Аның Ватаныннан киткәндә минем күңелгә әни турында җырлар, шигырь юллары килде.

Мин Витебск шәһәрендә "XX гасыр әниләре" дигән китап өстендә эшлим. Бу китап өчен Татарстанда яшәүчеләрдән дә әниләре, әбиләре турында җылы хатлар килсә әйбәт булыр иде. Моның өчен һич тә профессиональ язучы булырга кирәкми - гадәти хаттагыча иң якын, кадерле кешегез турында йөрәгегездән чыккан сүзләрнең һәммәсен дә сыйдырыгыз гына.

Татарстан җиренең әниләре! Ана дигән иң әһәмиятле вазифагыз турында безгә үзегез сөйләгез. Күп балалы аналардан, оныклардан хатлар көтәбез.

Әниләр, әбиләр, үзегез сөйгән хатын - кызлар турында ихлас күңелдән язылган шигырьләрегезне җибәрегез. Хатларыгызны проза телендә дә язсагыз була, чөнки ул барыбер ана турында җырга тиң.

Хатларны, әниләрегез һәм әбиләрегезнең фотосурәтләрен редколлегия китап өчен файдаланачак. XXI йөз әниләре әбиләре һәм әбиләренең әниләре яшәешен белергә тиешләр. Ә төрле милләт аналарының тормышы һәр игелекле зат өчен гыйбрәтле вакыйга ул.

Хатларыгызны түбәндәге адреска җибәрегез:



***Корнелюку Константину Степановичу. пр. Московский, 74 - 1, 2 ящик. г. Витебск - 35, 210035. Белорусь.***

# БАЛАЛАР ИҖАТТА ТӘРБИЯЛӘНӘ

***"Росинка" мәктәпкәчә балалар учреждениесенең оештырылуына ноябрь аенда 25 ел тула.***

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре мөдирләренең чираттагы район киңәшмәсен "Росинка" бакчасында үткәрүебез алдан ук билгеләнгән максатка хезмәт итте.

Киңәшмәнең төп темасы нәкыш сәнгатенә багышланган иде. Анда балалар иҗатын мәктәпкәчә учреждениеләрне бизәүдә файдалану, шуның белән һәр баланың үзе тәрбияләнә торган шартларны үзгәртүгә өлеш кертүенә ирешүне күздә тотты ул. Тагын бер әһәмиятле ягы - бу бакчада башкалар өчен гамәли үрнәк булырдай изостудия эшли. Аңа 29 ел стажга ия булган педагог, сәләтле иҗади шәхес - Анна Михайловна Ибәтуллина җитәкчелек итә. Бу студиядә балалар сәнгатьнең күп төрләрендә үзләренең көчләрен сыныйлар, иҗади эшләргә өйрәнәләр. Рәсем ясаудан тыш монда декоратив сәнгать, күләмле уенчыклар, кызыл балчыктан әвәләп сыннар ясау һәм аларны бизәү белән шөгыльләнәләр. Студиядә эшләү, иҗат итү өчен кирәкле барлык әсбапларны тәрбиячеләр коллективы үзе ясаган. "Иҗади хезмәтнең ахыргы нәтиҗәсен күрү - тәрбиядә иң мөһиме",- дип саныйлар тәрбиячеләр. Балалар бакчасында оештырылган картиналар галереясы нәкъ менә шушы максатка ирешүдә сыналган бер чара булып тора.

Район күләмендәге киңәшмә булган көнне дә коллегалары коллективның хезмәтенә шушы яклап зур игътибар юнәлттеләр, үзләре өчен файдалы үрнәк тәҗрибәсе белән таныштылар. Зурлар төркемендә үткәрелгән ачык дәрес "Бакчабызга бездән бүләк" дип аталган иде. Балалар бу дәрестә юбилейга бүләк итеп зур күләмле уенчык ясадылар. Дәрес ахырында аларның үз иҗат җимешләренә сокlануын һәм шушы бәйрәмгә өлеш кертүләрен аңлап, чын күңелдән куануларын күрдек.

**Р.ХӘСӘНШИНА,**
**район мәгариф бүлеге методисты.**

# Әмзә уңганнары

## ПОХАЧЕВМЫ? ДИМӘК, МЕХАНИЗАТОР!

Авылда шулай диләр: Похачев икән, димәк, ул техниканы биш бармагыдай белергә, егылып киткәнче эшләргә тиеш!

Фамилия турында шундый күзаллау мәрхүм Анатолий дәдәйдән килә. 40 ел "Комбайн" колхозында тракторчы булып эшләп, үзенә күп мактаулар яулаган кеше иде ул. Андый ата янәшәсендә үскән малайларның механизатор һөнәрен сайлавына беркем гаҗәпләнмәде. Башта Александр тракторга утырды, Юрий да техника тирәсен үз итте: бригадирның техника буенча ярдәмчесе булды, хәзер инде трактор йөртә. Александр Анатольевич 1976 елдан бирле механизатор булып эшли, ЮМЗ - 6ны иярли (рәсемдә). Кыш буе хуҗалык фермасы карамагында була, төрле нарядлар үти. Яз,җәйге көннәрдә - чәчү, азык әзерләү, чөгендер алу кебек мөһим эшләрнең берсендә дә катнашмыйча калмый. Хәзер фермага салам ташый, юлсызлык - карсызлык чорында да малларны азыктан өзмәү өчен тырыша.



Похачевларның интернациональ гаиләсендә өч бала үсә, алар арасында, һичшиксез, тракторны биш бармагыдай белүчесе шулай ук булмый калмас. Гаилә башлыгы да, хатыны Гөлчәчәк тә (ул хат ташучы) моңа һич каршы төшәргә җыенмыйлар. Ә нәрсә, Похачев икән, ул техниканы белергә тиеш ләбаса! Ахыр чиктә бу нәтиҗәне авыл халкы үзе ясады бит!



## КӨРӘШЧЕ ТОКЫМ

Ә менә Гатиннар авыл тарихына көрәшче токым булып кереп калырлар ахрысы. Шамил Заһитович (рәсемдә) - байтактан авыл сабантуйларында мәйдан тотучы кеше. Соңгы ике елда батыр калып, сабантуй тәкәсен дә ул яулады. Үсеп килүче ике улы - Рияз белән Равил дә хәзердән келәмдә көч сынашалар. Риязы район яшь көрәшчеләр бәйгесендә призлы урын да алып өлгерде инде.

Әлбәттә, көрәшче рухлы кеше хезмәттә дә сыната торган булмый. Гатинның механизатор булып эшләвенә киләсе елга 20 ел тула. Галәмәт тә егәрле, булдыклы механизатор ел әйләнәсенә "корыч айгыры"ннан төшми. Кыш барда, патока ташый, сезонында чәчүдә, чөгендерләрне кагатларга ташуда эшли, әле менә мәктәпкә ягулык ташу белән мәшгуль. Бер эштә дә үзенә тел - теш тидерергә урын калдырмый ул. Гаиләсендә дә ата сүзе белән исәпләшәләр. Гатиннар төп йортта, әниләре Фәһимә әби белән бергә яшиләр. Үзара хөрмәт өч буынны да тату гаилә итеп берләштерә бит ул: әбинең - үз урыны, килен кеше Рәмзиянең - үз дәрәҗәсе, ата белән уллар да йорт өчен янып яшиләр. Тату Гатиннарның тормышына күпләр соклана. Ә авыл кешеләре бер - берсенә бәяне бик белеп бирәләр инде ул!

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**
**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

# «МОҢСЫЗ ЯШӘҮ ЯШӘҮ ТҮГЕЛ УЛ»

***Героебызның фотосын баянсыз күз алдына китерү мөмкин түгел. Тормышы, иҗаты, бүгенге яшәеше, киләчәккә омтылышлары да музыка сәнгате, аерылмас дусты баян белән тыгыз бәйле аның.***



Тәлгать Сәфәргалиевич үзенең аңлы тормышын 4 этапка бүлеп карый. Беренчесе - 1966 елда Кизләү урта мәктәбен тәмамлап, Урта Чаллы клубы мөдире булып эшләгән еллары. Махсус белеме юк. Әмма кулында - гармуны (авыл яшьләре өчен үзе хәзинә!), күңелендә - зур теләге булган кеше барыбер мәдәният дөньясында нидер эшли ала икән. Авыл клубының яңа бинасын өлгертәләр, кичләрен клуб гөрләп тора. Шул елларда республика Халык иҗаты йортында баянчылар курсын тәмамлый. Бу еллар Бадыйгинга кешеләр белән аралашу, аларның психологиясен, нинди җан азыгына сусавын аңлау күнекмәләре бирә. Әмма теоретик әзерлек, һөнәри белем җитмәү үзен торган саен еш сиздерә, һәм ул 1970 нче елны Тәлгать Сәфәргалиевичны мәдәният институтының халык уен кораллары оркестры бүлегенә китерә. Беренче елын гына эшли башлаган бүлектә музыкаль грамотасыз, әзерлексез бары 2 генә студент, шуның берсе - Тәлгать була. Шуңа музыка дөньясының теоретик кыяларын яулау бик зур киеренкелек, хезмәт сорый, һәм соңгылары үз җимешен китерә дә.

1974 елдан Т.С.Бадыйгин өчен өченче чор - һөнәри белемеңне һәр өлкәдә, һәр жанрда сынау чоры башлана. Халык белән эшләү тәҗрибәсе бар, белем җитәрлек, теләк зур. 5 ел буе Т.С.Бадыйгин район мәдәният йорты методисты вазифасында шул өч алшартны эшкә җигеп, рәхәтләнеп мәдәниятка хезмәт итә. Район мәдәниятын фидакарь зат К.В. Изотова җитәкләгән еллар. Шәһәрдәге һәр зур оешмада, авыл клублары каршында хорлар, вокаль ансамбльләр эшләгән, иҗат отчетлары гадәткә кергән чак. Һәр коллектив концерты хор чыгышыннан башлана, соңыннан 250 - 300әр кешене берләштергән җыелма хор җыры белән тәмамлана. Алар белән нигездә Т.С.Бадыйгин шөгыльләнә, училищедан хор классын тәмамлаган белгечләр ярдәмгә киләләр. Кичләрен баянын күтәргән Бадыйгинны НУРБ, шикәр заводында, ерак авыл клубларында күрергә була. Тәлгать Сәфәргалиевич НГДУның дүрт - биш тавышка акапелла җырларлык булып җитешкән хорын бүген дә сагынып искә ала. Иске Чаллыда парторг Г.Ш. Нургалиев үтенече буенча 4 ай буе хор коллективы, Колбай Морасада вокаль ансамбль әзерли.

Мәдәнияттагы бу иҗади хәрәкәт үз җимешләрен дә озак көттерми. 1977 елда район хор коллективы Совет властеның 60 еллыгы уңаеннан үткәрелгән Бөтенроссия смотрында лауреат исеменә лаек була. Соңрак Тәлгать Сәфәргалиевичка үзе әзерләгән коллективлар белән күп җирдә чыгыш ясарга, күп җиңүләргә ирешергә насыйп була, әмма беренче җиңүләре барыбер иң якыны булып саклана аның күңелендә.

Бу елларда күп талантлы кешеләр белән очраша ул, күбесенең районда үз урынын табып, ныгып кала алмауларына бүген дә йөрәге әрни. Биюче А.М.Изотов гаиләсе - шул үкенечнең иң кызганычыдыр, мөгаен.

1978 елда аңа балалар музыка мәктәбен җитәкләүне тапшыралар. Бу - Т.С.Бадыйгин тормышының 4нче этабы һәм ул үз эченә төп - төгәл 20 ел гомерне сыйдыра! Бу инде - һөнәрмән буларак җитлеккән, тәҗрибә туплаган зирәклек чоры.

Район пионерлар йортына сыенган мәктәпнең бүгенге сәнгать йортына күчкәнче бар тормышы - проблемалары, уңышлары - һәммәсе яхшы таныш директорга. Вакытлыча дип күченгән элекке НУРБ УККсы бинасында алар 15 ел яшиләр. Яңа мәктәп төзү хыялы, омтылышы 1976 - 77 еллардан бирле булса да, аның гамәлгә ашуы акрын бара. Сиксәненче еллар ахырында 4 ел буе проект ясала, аннан Министрлар Советы капиталь төзелеш бүлеге планына кертелә. Нигезе салынгач та төзелеш 2 ел үзенә чират җиткәнне көтә. Бәхеткә, ТР Премьер - министры Ф.Х. Мөхәммәтшин безнең районнан депутат итеп сайлана, бәхеткә район руленә тынгысыз үҗәт җитәкче Ф.С. Сибагатуллин килә... Төзелешнең хәлиткеч язмышы аларның кодрәтле куллары белән хәл ителә. Ә бинаны матурлык, сәнгать белән тәрбияләү сарае итеп, белгеч таләбе һәм иҗади зәвык күзлегеннән җиһазлау - моңа һичкем каршы килмәс!- нәкъ менә Т.С.Бадыйгинның хезмәте җимеше. Төзелешкә коррек-

### Портрет

тировканы байтак кертергә туры килә аңа, шөкер, 547нче ПМК төзүчеләре каршы килмиләр. Зур холлны бүлеп, ике класс ясарга килешәләр. Стеналарга буяу урынына затлы килешле обойлар ябыштыралар. Музыка кораллары алу өчен директор Санкт - Петербургка кадәр барып җитә. Бәхет димә: аның идеясенә матди хуплауны сөйләшеп кайтканның икенче көнендә үк Фәрит Хәйруллович үзе бирә! Һәм ул үз дигәненә ирешә: чагыштырмача арзан бәягә 10 пианино, 3 кабинет рояле, 1 концерт рояле, банкеткалар, өстәлләр - һәммәсен шуннан эшләтеп ала. Җиһазлар алуга да җаваплы карый: уңайлы, зәвыклы, затлы һәм... арзан булсын! Озак эзләгәч, Яр Чаллы шәһәрендәге "Фәйзи" фирмасына килеп чыга. Директор парталар, өстәлләр, бию залы җиһазларын, көзгеләрне - һәммәсен шуннан эшләтеп ала, төсен, формасын, үлчәмен үзе сайлый, аны китереп күрсәткәч кенә төзәтмәләр кертеп тулы заказын бирә. Шулай итеп, Бадыйгин үз күңеленә ошаган җиһазлар тапса, эшмәкәрләр шулай ук үзләре өчен яңа ачыш ясыйлар: партаның бу рәвешлесе дә була, өстәлнең бу формасы - аерата килешле килеп чыга икән!

Мәктәпнең бүгенге йөзе шулай туа. Хәзер директор аның иҗади йөзен камилләштерүне максат итеп куя. Музыка мәктәбенә эш - гамәлләре белән район, шәһәр масштабына чыгар чак җитте. Дәрестән тыш чараларны баету кирәк. Планнары бар, яңалары да туа тора: декабрьдән абонемент буенча хезмәт күрсәтү кертеләчәк, профессиональ музыкантлар, җырчылар белән очрашулар планлаштырыла. (Минем бу гамәлләр арасында район мәдәният йорты бинасында планлаштырылганнарын да бик күрәсем килә килүен!) Хәзердән Кормыш микрорайонында мәктәпнең филиалын ачу мөмкинлеге булмасмы, дип тә эзләнәләр һәм, билгеле, боларның башында гел шул Бадыйгин тора. Һәм шул мәшәкатьле көннәрендә дә район мәдәни тормышыннан читләшми.

Өч яшеннән абыйсы гармунын тартып үскән, гомер



буе баяннан аерылмаган Тәлгать Сәфәргалиевичның күңелендә моң тумый дисәк, кем ышаныр иде микән? Аның үз моңы үз тавышы булып җырларына күчә, бүген Бадыйгинның үзе язган 20ләп җыры бар. "Әллә инде" романсы, "Бездән әле яшьлек узмады", "Юксыну" һ.б. - төрле характердагы җырлар булсалар да сүз һәм моң бирелеген, рухи тойгылар муллыгын тыңлаучыга тиз җиткерәләр. Аларның һәрберсе үзенчә якын, үзенчә кадерле авторга. Әмма үзе шулай да җырының иң әйбәте әле язылмаган, әле алда дип саный.

Миңа калса, бу Бадыйгинның әле тулы иҗатта, хезмәттә яшәвен күрсәтә дә. Хәзер 50 яшен тутырырга җыенган атказанган мәдәният хезмәткәренең көч - куәте ташып эшләр, иҗат итәр чагы. Язмыш аңа тормышта үзе төсле үк талантлы Зөлфия ханымны биргән. Бу хатын - кызда җыр таланты, хуҗабикә таланты, башлаган эшне ахырынача җиткерү, акыл,тугрылык таланты гаҗәеп муллык белән гәүдәләнгән. Ул шул ук сәнгать, мәдәният ыгы - зыгысында кайный, озак еллар мәктәпнең вокаль ансамблендә җырлый, Тәлгать аганың үз дөньясына кагылмыйча тормышын тулыландыра, янәшә атлый, кирәк чакта киңәш бирә, кирәксә сабыр итә белә. Гөрләшеп үскән ике кыз - капма - каршы холыклы Айгөл белән Зөлфинә - Бадыйгиннарның багъ алмалары. Тагын бик күп дуслары, мәңге картаймас "Ветеран" хорының моңга гашыйк әбиләре, гөлт иткән дача бакчалары, күпсанлы шәкертләре һәм, иң мөһиме, туасы көннәре, эшлисе эшләре, сөясе балалары, гаилә башлыгының шушы көннәрдә билгеләп үтәсе ярты гасырлык юбилее бар. Һәм - уртак җырлары, моңнары. Бадыйгиннар өчен моңсыз яшәү - яшәү түгел ул.

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**
**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

# УКЫТУЧЫ ДА, ОСТАЗ ДА

Менә дигән укытучы, яшьләр остазы Валентин Николаевич Егоров Чулпан мәктәбендә 33 ел эшләде. Физика һәм математика укытучысы ул, бер үк вакытта технология дәресләре дә алып бара. Валентин Николаевич һәр дәрестә материалны үтемле иттереп, тырышып аңлата, укучыларда материалны аңлап кабул итү күнекмәләре формалаштыра. Үз эшендә укытуның төрле алымнарын куллана ул, балаларны мөстәкыйль рәвештә белем алырга да өйрәтә. Технология дәресләрендә Валентин Николаевич малайларга үзенең бар осталыгын тапшыра, аларны кораллар белән кыю, ышанычлы эш итәргә, шул исәптән кыру станогында эшләү күнекмәләренә дә өйрәтә.

Укучылар Валентин Николаевичны таләпчән һәм гадел булганы өчен дә яраталар һәм хөрмәт итәләр. Эшли башлаганнан бирле класс җитәкчесе дә ул. Һәм укучылар белән үзара аңлашулы мөнәсәбәт урнаштыру өчен көчен дә, вакытын да кызганмый: класс белән экскурсияләргә, походларга йөри, узган уку елы ахырында алар ике көнлек туристик сәяхәттә булып кайттылар.

Сүз дә юк, авылдашлары арасында да абруй һәм хөрмәткә ия ул. "Иң интеллигент ир - ат, менә дигән гаилә башлыгы" - чулпанлылар аның турында әнә шулай диләр. Һәм бу сүзләрдә хаклык бар, чөнки авылда бөтен кеше дә халык күз алдында бит. Валентин Николаевич хатыны Лидия Ивановна белән бергәләп 4 бала үстерделәр: 3 кызлары тормышта инде, ә уллары Алабуга педагогия институтында укый. Егоровларның балалары да әти - әниләреннән күп кенә кешелеклелек сыйфатларын үзләренә дә алганнар һәм аларның йөзенә кызыллык китермиләр.

Валентин Николаевичны 60 яшьлек юбилее белән котлап, аның моннан ары да шулай энергияле һәм ягымлы, тормыш сөючән оптимист булып калуын телибез. Тазалык - саулык сезгә, коллегабыз, гаилә тынычлыгы һәм балаларыгызның да, оныкларыгызның да игелеген күреп, үзегез дә аларны куандырып яшәвегезне телибез.

**Н.ГАНИЕВА,**

**Чулпан урта мәктәбе директорының укыту -тәрбия эшләре буенча урынбасары.**



**Рәсемдә: В.Н.Егоров 1996 елгы чыгарылыш класс укучылары белән.**

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Югары Нурлат авылында яшәүче ***кадерле әтиебез Фәйзулла һәм әниебез Нурия Хәбибуллиннарны*** 70 яшьлек юбилейлары белән котлыйбыз. Сезгә исәнлек - саулык, тыныч, бәхетле - шатлыклы көннәр телибез.

Кешелекле бит сез,
Олы җанлы, ярдәмчел сез,
дуска, туганга.
Сездән газиз кеше,
белмим, бармы,
Без бәхетле тик сез булганга.



**Иң изге теләкләр белән, балаларыгыз, киленнәрегез,киявегез, оныкларыгыз исеменнән: кызыгыз Фәния,киявегез Дамир, оныкларыгыз Румир һәм Алинә.**

***Бөтен дөнья галимнәре таныганча, җәмгыятьнең сәламәтлек дәрәҗәсе беренче чиратта ул яшәгән системада әйләнә - тирә мохиткә мөнәсәбәт, табигатькә караш белән турыдан - туры бәйләнгән. Мәгълүм ки, кешенең сәламәтлеге ни эчүдән, ни ашаудан, ни сулаудан тора. Безнең “ата - улны, ана - кызны белмәгән” тәртипсез җәмгыятебездә дә...***

# Без - дөньяда иң кадерсез халык

Россиядә 1992 елдан башлап, сугыштан соң беренче тапкыр халык саны кимүгә йөз тотты.

1996 елда бездә дә алга киткән илләр һәм БДБ дәүләтләре арасында үлүчеләр саны буенча иң югары, туучылар саны буенча иң түбән күрсәткечләр теркәлде. Туучылар санына килгәндә, Россия дөньяда иң соңгы урыннарның берсендә тора: бер елга мең кешегә 9 яңа туган бала туры килә. Шуның өстенә, яңа туган һәр 100 нарасыйның икесе биләүдә үк үлә. Балалар бик еш авырый: статистика буенча 100 балага бер елга 150 авыру туры килә. Бу - бездә бөтен балалар елга бер, ә һәр икенче бала елга ике мәртәбә авырый дигән сүз. Мәктәп укучыларының 40 проценты хроник авырулардан интегә, 10 укучының берсен генә сау - сәламәт диеп әйтергә була. Авыру сәбәпле, һәр өченче үсмер хәрби хезмәттән азат ителә.

Әзме - күпме алга киткән һәм үсеп килүче илләр арасында Россия уртача гомер озынлыгы буенча иң соңгы урында тора. Бездә ирләрнең гомер озынлыгы - 55, хатын - кызларныкы - 71 ел. Бу күрсәткеч - илдәге тормыш дәрәҗәсен билгели торган төп күрсәткеч. Хәер, үлем - китемнең артуы авырулардан гына тормый. Монда төрле бәхетсезлекләрне, үтереш, үз - үзеңә кул салуларны да исәпкә алырга кирәк.

1996 елда гына да Россиядә 77 мең кеше (аларның күбесе - ирләр) үзенә кул салган. 1997 ел башында илдә 11 миллион (халыкның 7 проценттан артыгы) инвалид булып исәпләнгән. Ел саен һәр 100нче кеше гариплән. Инвалидларның 85 - 90 проценты - эшкә яраклы яшьтәгеләр, һәр алтынчысына 45 яшь тә юк.

Бүген Россиядә 1 эшләмәүчегә 1,8 эшләүче туры килә. (1939 елда СССРда бу сан 1гә 6 булган). Зурлар арасында бер елга 100 кешегә 100 авыру очрагы туры килә. Мәгълүм булганча, организмның сәламәтлеген иммунитет (авыруга каршы тору) системасы билгели. Россия Медицина фәннәре академиясе мәгълүматларына караганда, бездә зурларның 40 процентында иммун системасының бозылуы күзәтелә.

Башка илләр белән чагыштырганда, экология, табигатьне саклау юнәлешендә Россиядә "бармакка бармак та сугылмый". Экспертлар раславынча, эчә торган су хәтта юынырга да ярамый: андагы авыр металлар һәм башка химик элементлар тирене ашый. 6 миллионнан артык кеше югары радиация шартларында гомер кичерә. Халыкның 70 проценты стрессларга дучар. Уртача бүлеп исәпләгәндә, 1996 елда илдәге һәр кеше (бәбиләрне, бабайларны да кертеп) 25 шешә аракы эчкән!

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы тәкъдиме буенча, дәүләтнең барлык милли керемен кем дигәндә 5 проценты халыкның сәламәтлеге турында кайгыртуга тотылырга тиеш. АКШта бу максатларга әлеге керемнең 14 проценты ( елга 1 триллион доллардан артык) тотыла; бу сан Россиянең бөтен еллык кеременнән дә артык. Безнең дәүләт сәламәтлек саклауга бөтен милли керемнең 2,3 процентын бүлеп бирә. Бу сан - Көнбатыш Европаның барлык илләре, элекке социалистик лагерьга караган дәүләтләр һәм барлык БДБ илләре арасында иң түбән күрсәткеч. Чынлыкта исә сәламәтлек саклауга шушы билгеләнгән акчаның да ел саен 75 - 80 проценты гына тотыла. Бу Россия дәүләтенең сәяси кыйбласын янә бер кат күрсәтә...

**Гөлнар ҖӘЛАЛОВА.**
**("Шәһри Казан"нан).**

## СПОРТ СПОРТ

### ЯШЬ КӨРӘШЧЕЛӘР БИЛ АЛЫШТЫ



Көзге каникул көннәрендә балалар - яшүсмерләр физик хәзерлек клубында ДЮКФПның 7 командасы, аның филиаллары - Чулпан, Түбән Нурлат, Яңа Иглай, Югары Нурлат, Фома һәм Биккол авыл командалары арасында милли көрәш буенча ярышлар узды.

Анда барлыгы 80 укучы көч сынашты. Ярышларның максаты милли көрәшне популярлаштыру һәм иң көчле көрәшчеләрне ачыклау иде.

Ярышлар 11 категориядә (27 кг.нан алып 65 кг.га кадәр һәм югарырак үлчәүдә) 1981 елгы һәм аннан яшьрәк балалар арасында үткәрелде.

Илнар Гайнуллин, Марсель Гозәеров, Рәмис Гозәеров (ДЮКФП), Илшат Әһлиуллин, Зөфәр Мөхәмматов (Югары Нурлат), Илсөяр Ишниязов, Илфат Дәүләтчаров, Хафиз Вәлиев (Түбән Нурлат), Фәргать Фәйзуллин, Илшат Мингалимов, Ринат Нуретдинов (Чулпан) төрле үлчәү категориясендә җиңүчеләр булдылар.

Гомумкоманда ярышларында урыннар түбәндәгечә бүленде:

*I урын* - ДЮКФП (тренеры Р.Рәхмәтуллин),

*II урын* - Түбән Нурлат (тренеры Н.Вәлиев),

*III урын* - Чулпан (тренеры И.Насыйбуллин).

Җиңүчеләр грамоталар һәм призлар белән бүләкләнде. Мондый ярышлар матур традициягә әверелер дип ышанабыз.

**Р.РӘХМӘТУЛЛИН,**
**ярышларның баш судьясы.**

## *02 хәбәр итә 02 хәбәр итә*

*02 хәбәр итә 02 хәбәр итә*

### НАРКОТИКЛАР ҺӨҖҮМ ИТӘ

Милиция күзенә наркотиклар кулланучы яки аларны таратучылар, еш кына балигъ булмаганнар, әледән - әле эләгеп тора. Чираттагы рейд вакытында, әйтик, тимер юлчылар бистәсендәге бер гаражда кулланырга әзерләп куелган киндер запасы табыла. Сүз уңаеннан әйткәндә, аның бер шырпы тартмасы кулда яңа акча белән 50 сум тора икән. Эчке эшләр бүлеге хезмәткәрләре хәзер шушы эшне тикшерү белән мәшгульләр.

### ЮЛДАГЫ ҮЛЕМ

Көзгә кергәннән соң икенче тапкыр инде җигүле атны машина таптату очрагы булды. 5 ноябрь көнне Нурлат -Аксубай юлының 11 нче километрында каршы килүче транспорт уты алтынчы модель "Жигули" артындагы 35 яшьлек кешенең күзен чагылдыра һәм... Шул юлдан баручы атлы фаҗига урынында ук үлә.

### УРЛАШУ ХРОНИКАСЫ

Нурлаттагы тагын бер автоһәвәскәр зур каза күрде - бурлар төнлә аның "Москвич" машинасын ачып автомагнитоласын һәм аккумуляторын урлаганнар. Октябрь бәйрәме алдыннан гына Киекледә эшмәкәр М.ның кибетен басканнар. Тикшерү бара. Ә менә Биляр Озерода "ИЖ - Планета - 5" мотоциклын куып китүчеләр, "Таң" хуҗалыгы фермасыннан 15 килограммлы дуңгыз баласы чәлдерүче кебек үк, озакламый эчке эшләр бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан тоткарланалар.

## *"Дуслык" почтасыннан*

### МЕДИЦИНА ӘҺЕЛЛӘРЕНӘ РӘХМӘТ

Тормышта миңа төрлесен күрергә туры килде, гомер уза барган саен төрле авыруларга ешрак бирешә башладым. Шуңа күрә медицина әһелләренә мөрәҗәгать итүем дә ешайды. Менә бу юлы да участок табибына барырга туры килде. Тамара Васильевна Пермякова - бик игътибарлы һәм мөлаем кеше. Аның шәфкать туташы Любовь Михайловна Алифанова да шундый ук ягымлы. Аңа әле 30дан әз генә артык, 1983 елда Ульяновск медучилищесын тәмамлаган. Нурлатта 1986 елдан башлап эшли. Миңа уколлар ясатырга кушканнар иде, әмма моның өчен хастаханәгә йөрергә туры килмәде: Любовь Михайловна үзе килеп йөрде. Аның төгәллеге, пөхтәлеге кыяфәтеннән үк күренеп тора. Үзенең эшен дә бик яхшы белә. Ходай исәнлеген бирсен, берүк!

Безгә авыр вакытта ярдәмгә килүче медицина әһелләренә яхшылыклар гына телисем килә.

**А.КУЗНЕЦОВ.**
**Нурлат шәһәре.**


## БЕЛДЕРҮЛӘР

***Җәмәгать туклануы предприятиеләре хуҗалык исәпле берләшмәсе 1 нче ашханәдә минераль су һәм сыра шешәләре җыя.***

***

***19.06.97 елда 2нче мәктәп тарафыннан Станислав Геннадьевич Сибулатов исеменә бирелгән А сер. 1292296 номерлы аттестатны югалту сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.***


# КОТЛЫЙБЫЗ!



Нурлат шәһәрендә яшәүче **кадерле тормыш иптәшем, әтиебез Шәүкәт Әсхат улы Сафинны** туган көне белән тәбрик итәбез.

Уз әле тормыш юлыннан
Яшьлекне җигеп кенә.
Күңел тәрәзәләреңне
Шакысын бәхет кенә.
**Иң изге теләкләр белән**
**хатыны Рушания, кызы Алинә.**



Кормышта яшәүче **кадерле әниебез Сәгадәт Галиулла кызы Гатинаны** 60 яшьлек юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз.

Безгә биргән тәрбияң, назларың, җан җылың өчен чиксез рәхмәт, әниебез! Киләчәктә дә зур гаиләбезнең кадерле кешесе, сердәшебез булып тигезлектә һәм бәрәкәтле муллыкта сау - сәламәт, бәхетле гомер кичерүеңне телибез.

**Балаларың.**


## БЕЛДЕРҮЛӘР, РЕКЛАМА

### САТАБЫЗ

**"Алмалык" ширкәтендә йорты белән дача участогы, кыйммәт түгел.** Адрес: Совет ур., 183 - 92, тел.: 65-8-50.

***

**1 бүлмәле фатир.** Тел.: 5-19-05, көндезге 3тән соң.

***

**Ашыгыч төстә 1996 елгы ВАЗ - 2108.** Урта Камышлыга Красновка мөрәҗәгать итәргә.

***

**1995 елгы ВАЗ - 21061.** Тел.: 5-21-58.

***

**Капиталь гараж.** Тел.: 2-17-24.

***

**Декабристлар урамында 70нче йорт, пар белән җылытыла, челтәр газына тоташтырырга әзер. Йорт янь корылмалары, участогы, мунчасы бар. 1 яки 2 бүлмәле фатирга алмаштырырга мөмкин.** Тел.: 2-21-74, 5-21-86.

***

**Туй күлмәге, кыйммәт түгел.** Тел.: 2-19-71.

***

**Чкалов урамында 4 нче йорт.** Тел.: 2-21-75.

***

**Ашыгыч төстә чистарту корылмалары ягында капиталь гараж.** Адрес: Дружба ур., 78 - 45.

### САТАБЫЗ ЯКИ АЛМАШТЫРАБЫЗ

**1997 елгы ВАЗ - 21213. Яки азык - төлеккә алмаштырам.** Тел.: 2-11-13, көндезге 3тән кичке 7гә кадәр.

***

**ГАЗ - 3307 - 53. Яки җиңел автомобильгә алмаштырыла.** Адрес: Мәскәү ур., 34, тел.: 2-12-66.

### АЛМАШТЫРАБЫЗ

**2 бүлмәле фатирны - өстәмә түләп 1 бүлмәлегә.** Тел.: 5-27-55, кичке 6дан 7гә кадәр.

***

**Бер бүлмәле фатирны - өстәмә түләп ике бүлмәлегә. Шикәр заводы һәм тимер юл бистәләреннән тәкъдим итмәскә.** Тел.: 5-42-38.

***Идел Буе региональ наркология үзәге***

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.*

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга - 27нче ноябрь һәм 11нче декабрьдә көндезге сәгать 12дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.


"Дуслык" газетасы хезмәткәрләре, дуслары **Җәүһәрия Тимергали кызы Латыйпованың** вакытсыз үлүен тетрәнеп кичерә һәм мәрхүмәнең газиз балаларының, якыннарының авыр хәсрәтен уртаклаша.

Җәмәгать туклануы предприятиеләре хуҗалык исәпле берләшмәсе администрациясе һәм коллективы **әтисе** үлү сәбәпле Гүзәл Фазыл кызы Галимованың авыр хәсрәтен уртаклашалар.


МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19. Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2361 данә. 4398